**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында Ярлыкау мәсьәләләре буенча комиссия составына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә ярлыкау мәсьәләләре буенча комиссияләр турында» 2001 елның 28 декабрендәге 1500 номерлы Указы нигезендә, шулай ук вазыйфаларның атамалары үзгәрү белән бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Ярлыкау мәсьәләләре буенча комиссия турында» 2002 елның 31 гыйнварындагы ПУ-66 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2004 елның 19 июлендәге ПУ-479 номерлы, 2010 елның 11 гыйнварындагы ПУ-5 номерлы, 2010 елның 21 июлендәге ПУ-474 номерлы, 2010 елның 2 сентябрендәге ПУ-586 номерлы, 2011 елның 2 апрелендәге ПУ-181 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-626 номерлы, 2013 елның 7 мартындагы ПУ-208 номерлы, 2013 елның 16 декабрендәге ПУ-1234 номерлы, 2017 елның 20 июлендәге ПУ-637 номерлы һәм 2020 елның 27 гыйнварындагы ПУ-29 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында Ярлыкау мәсьәләләре буенча комиссия (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан К.Ф. Әмировны чыгарырга;

б) Комиссия әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Т.В. Забегинаның – «Эбиволь» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры, Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы рәисе урынбасары (килешү буенча)»;

Г.И. Сергееваның – «Бизнес коррупциягә каршы» иҗтимагый процедуралар үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы Иҗтимагый советының административ һәм гражданлык юнәлешләре буенча рәистәше (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 20 ноябрь
№ ПУ-769